**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 28 апрелендәге 1481 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 1 октябрендәге 2520 номерлы**
**«Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв**
**фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәне**
**раслау хакында»гы карарына**
**үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезләмәләренә туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 2520 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 26 ноябрендәге 4127 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә, 4 пунктына бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«- югары әзерлек режимы кертелгәндә, авария-торгызу эшләрен һәм башка чараларны, шулай ук мондый хәлләрдән килгән зыяннарны бетерү буенча чаралар үткәрүгә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**